**Халык җыены карары**

**30.11.2022 ел** **№3**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Белопахотный торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 30.11.2022 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:«2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Белопахотный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Белопахотный торак пунктында җәйге вакытта территорияне чаптыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 35 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 35 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 35 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлегенең Белопахотный торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2.Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга: «2023 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Белопахотный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә

әгъзаларыннан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәг мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

- Белопахотный торак пунктында җәйге вакытта территорияне чаптыру (килеш буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

3. Коноваловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының (http:/ menselinsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң ун көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге башлыгы ____________С.А.Билалова

